| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>20 августа 2015 года | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>№556 |

2015 елның беренче яртыеллыгында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Финанс – бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе урынбасары Т. М. Ламбинаның 2015 елның беренче яртыеллыгына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты резерв фондының акчаларын тоту турында мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясына, 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль Законга, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. 2015 елның беренче яртыеллыгына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында мәгълүматны игътибарга алырга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

***2015 елның 1 июленә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту турында мәгълүмат***

| ***№ п/п*** | ***Түләүне билгеләү*** | ***Сумма (сум)*** |
|---|---|---|
| 1 | Янгыннан зыян күрүчеләргә матди ярдәм күрсәтү | 119 300,00 |
| 2 | Дәвалану өчен матди ярдәм күрсәтү | 480 000,00 |
| 3 | ".. үлем белән бәйле” матди ярдәм күрсәтү | 20 000,00 |
| 4 | Башка төр матди ярдәм күрсәтү | 469 624,10 |
| 5 | "Берләшкән шәһәрләр һәм җирле хакимият Бөтендөнья оешмасының Евразия региональ бүлекчәсе " Халыкара ассоциациясенең 2014 ел өчен ел саен уздырыла торган әгъзалар кертемен түләү | 72 000,00 |
| 6 | “Созвездие-Йолдызлык-2015” XV ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестиваленең зона финалында призлы урыннар алган мәдәният, спорт һәм мәгариф учреждениеләре иҗат коллективлары җитәкчеләре һәм педагогларына матди түләүләр | 156 500,00 |
| 7 | "Татарстан Республикасы муниципаль районының Мактаулы гражданины", "Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы казанышлары өчен" исемнәре өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата премия түләү | 55 000,00 |
| 8 | Мәктәп формасы алуга матди ярдәм күрсәтү | 15 000,00 |
| 9 | Украина территориясен ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Зеленодольск муниципаль районы территориясенә килгән Украина гражданнарына матди ярдәм күрсәтү. | 5 743,00 |
| | ***БАРЛЫГЫ*** | ***1 393 167,10*** |

ЗМР Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе О.П.Дёгтева